Галиуллина Г.Р.
Казан шәһәре

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕ ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕ ӨЛКӘСЕНДӘ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ БЕР КАРАШ

Г. Ибраһимов татар милләтенең рухи тормышын, милли мәдәниятен, гуманитар фәнен баетуга алыштыргысыз өлеш керткән әдипләрнең беренче рәтендә йөри. Аның күпкырлы эшчәнлеге татар телен фәнни югарылыкка күтәрү, татар тел белеменең методологик нигезен эшләүгә юнәлгән. Татар тел белемендә кабатланмас эз калдырган әдипнең эшчәнлеге үз эченә татар грамматикасының теоретик һәм гамәли якларын, фонетика һәм орфография, тел тарихы, татар телен укыту методикасы, башка төрки телләрнең үсешенә бәйле мәсьәләләрне ала. Галимнең саналып киткән өлкәләрдәге эшчәнлеге бүген дә әһәмиятен югалтмаган, киресенә, аларның күбесе хәзерге татар тел белеме фәне өлкәсендәге бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндә кыйммәтле чыганак булып торырлык.

Без Г. Ибраһимовның татар лексикологиясе өлкәсендәге эшчәнлегенә бәйле кайбер мәсьәләләргә аерым тукталырга булдык. Күренекле әдип үзенең һәм гыйльми, һәм публицистик, һәм әдәби-тәнкыйди мирасы аша татар теле лексикологиясен фәнни дәрәҗәгә күтәрү, татар теленең лексик байлыгын пропагандалау өлкәсендә өзлексез эшли. Әдәби әсәрләрендә ул татар теленең төрле лексик катламнарына караган сүзләрне, кабатланмас сурәтләү чараларын, халык авыз иҗаты ядкарьләрен уңышлы куллану белән татар халкының милли сыйфатларын, психологиясен, дөньяны күзаллау үзенчәлекләрен гаять дәрәҗәдә төгәл һәм тулы рәвештә ачып сала алган. Халыкның җанлы сөйләм телендә иҗат ителгән әдәби мирасы татар теле лексикасының чиксез байлыгын, мәгънә тирәнлеген чагылдыра.

Г. Ибраһимов үзенең төп кыйбласы итеп саф татар телен алга сөрүне сайлый. Әдәби мирасында бу образ, сурәт тудыру үзенчәлекләрендә чагылса, фәнни эшчәнлегендә исә XX гасыр башы татар тел белеменең көнүзәк

мәсьәләләренә багышланган эшчәнлегендә ачык күренә. Татар милләтенең рухи, икътисади, иҗтимагый-сәяси тормышында  кискен борылышлар чоры саналган XX гасырның беренче унъеллыгы татар гуманитар, шул исәптән тел белеме фәннәренең үсешендә билгеле чор санала. Татар әдәби теле үсеш юнәлешләренә бәйле фикер төрлелегендә Г. Ибраһимов милли тел нигезендә халыкның җанлы сөйләм теле ятарга тиешлеген ассызыклау белән аерылып тора. Татар теле лексикологиясенең бер тармагы саналган терминология өлкәсенә бәйле эшчәнлегендә бу ачык күренә. Мисал өчен, үзенең «Татар сарыфы» китабына язылган кереш сүздә ул болай дип язды:  «... Минем бөтен мәнбәгым – саф татар теле булды. Кулымнан килгән чаклы, телемезнең эченә, төбе вә рухына керергә, андагы хасият вә мөнәсәбәтләрне табарга вә шундан алга алган нәтиҗәне мәйданга куярга тырыштым» (2,12). Г. Ибраһимовның бу өлкәгә караган төп принциплары хәзерге татар терминологиясен эшләүдә дә төп нигез булып торырлык. Аерым алганда, галим татар тел белеме терминологиясен эшләү барышында түбәндәгеләргә нигезләнә: 1) тел белеменең терминологик аппараты җиңел аңлашыла торган татар сүзләреннән торырга тиеш. Шул ук вакытта әдип телнең үз байлыгында теге яки бу терминны бирерлек сүз булмаганда, зарур урыннарда башка телләрдән термин алу мөмкинлеген кире какмый; 2) сүзнең лексик мәгънәсе белән терминологик мәгънәсе арасында бераз аерма булырга тиеш, ягъни термин ясаганда гомумкулланылыш сүзенең тышкы формасына үзгәреш кертү һәм лексик мәгънәнең бер семасын гына алга сөрү мөмкинлеге ассызыклана. «Фәнни терминологиянең милли тел кысаларында үсеше халыкның үз телен асыл итеп алып, мәҗбүрият булмаган  урында чит сүзне кертмәүдән гыйбарәттер» (1, 88). Хәзерге татар терминнар системасына күз салсак, төгәл фәннәр өлкәсендә генә түгел, гуманитар фәннәр терминологиясе дә үзенең чуарлыгы, татар теленең табигый үсешенә зыянлы булуы белән аерылып тора. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында татар теленең лексик системасында барган кискен үзгәрешләр, телнең сүзлек составына уңай йогынты ясау белән бергә, телебезнең табигый агышына да шактый зыян китерде. Бернинди киртәләргә юлыкмыйча,

телебезнең лексик составына килеп кереп, бик тиз арада актив кулланыла башлаган алынма сүзләрнең киң таралышы иң башлап телебезнең терминнар системасында күзәтелә. Аерым галимнәр, әдипләр тарафыннан татар теленең лексик байлыгына нигезләнеп терминнар ясарга омтылыш та әлегәчә уңай нәтиҗәләргә китермәде. Моның төп сәбәбе – телебезнең үсеш закончалыкларын тиешенчә исәпкә алмау, термин буларак татар халкы арасында киң таралган, мәгънәсендә экспрессия көчле булган гомумкулланылыш яисә гади сөйләм сүзен тәкъдим итү. Терминология өлкәсендә булган төп проблемалар бары тик фәнни якын килеп, танылган әдипләребез, галимнәребез калдырган мирасны җентекле өйрәнелеп кенә хәл ителә ала.

Бу җәһәттән Г. Ибраһимовның тел сафлыгына карашы үзенчәлекле. 1910 нчы елда «Йолдыз»да чыккан «татар теле һәм татарча язу хакында бер-ике сүз» мәкаләсендә телебезгә үтеп кергән алынма сүзләргә карата фикерләре хәзерге татар теле лексикасы өчен дә бик актуаль. Аерым алганда, пуризм хәрәкәте тарафдарларының татар телендә кулланылып килә торган алынма сүзләрне татарчалаштыру юнәлешендәге эшчәнлеген тәнкыйтьләп, «...садә телдә язуның мәгънәсене һич бер чит лөгать кертмәү дип аңлау билкөлле хата идеке мәгълүм булса кирәк. .<...> Гыйльми вә фәнни нәрсәләр язганда, чит лөгатьсез бер эш тә чыгарып булмый. Бу фәкать бездә генә түгел, һәр милләттә шулайдыр. Бөтен әдәбиятны фәкать үз лөгатендә генә язу һич бер милләткә мөяссәр дәгелдер. <...> Садә язу дип, бөтенләй татарчалашып беткән чит сүзләрне алыштырырга омтылу урынсыздыр» (1, 79-80).

Г.Ибраһимовның әлеге мәкаләсендә вакытлы матбугатта алынма сүзләрне урынсыз куллануны тәнкыйтьләгән фикерләре хәзерге татар матбугаты өчен дә бик урынлы. Бүгенге матбугат битләрендә күпләп кулланыла торган гарәп-фарсы, европа телләреннән кергән бер төркем алынмаларның киң җәмәгатьчелек өчен авыр яисә бөтенләй аңлаешсыз булуы мәгълүм.

Татар әдәби теленең халыкның җанлы сөйләм теле нигезендә үсәргә тиешлеге 1924 нче елда сөйләнгән «Татар телен җиңеләйтү турында тезислар»ында тагын да ачыграк чагыла. Әлеге докладта яңгыраган татар

теленең үз лексик байлыгын киңрәк кулланылышка кертергә, татар теленең эчке ресурсларының барлык мөмкинлекләрен файдаланырга, аерым төшенчәләрне атау өчен телебездә сүз булмаган очракта башка төрки телләргә мөрәҗәгать итәргә, мәгънәләре аңлашылмаган алынма (гарәп-фарсы) сүзләрен кулланылышка алмаска кебек төп принциплар хәзерге татар телен, аның лексик байлыгын һәм терминологиясен өйрәнү, системалаштыру һәм үсеш юнәлешләрен ачыклау барышында нигез булырлык.

Искәрмәләр:


1. Ибраһимов Г.Г. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма әсәрләр / Галимҗан Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2007. – 239 б.
2. Ибраһимов Г. Татар сарыфы /Төз. Ф.С. Сафиуллина, Б.Э. Хәкимов. – Казан: Казан дәүләт университеты, 2009. - 118 б.